ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылы торак пунктында 2025елда үзара салым керту турында

2025 елның 12 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештырунның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Янурыс авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Янурыс авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан махсус хәрби операция барышында һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Су башнясын буяу, терәк кую, нигезне салу;
2) МТЗ-82 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү, асылмалы җайланма сатып алу).
3) Брусчатка салу, Янурыс мәдәния йортының керү төркеменә бетон салу (төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, хезмәт өчен килешү буенча түләү).
4) Янурыс т. п. һәйкәленә мемориаль такталар сатып алу, урнаштыру; (хезмәт өчен килешү буенча түләү);
5) Иске Әхмәт торак пункты юлларына вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак ташу һәм салу, грейдерлау);
6) Иске Әхмәт зираты өчен эш инвентаре сатып алу;
7) Хуҗасыз территорияләрдә, юл буенда эре агачларны һәм куакларны кисү (хезмәт өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева